ҮЧТЕКИ

ҮЧТЕКИ

ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫННАН



Бу бармак – бабай,
Бу бармак – әби,
Бу бармак – әти,
Бу бармак – әни,
Бу бармак – нәни бәби,
Аның исеме – Чәнти.

Карга килер – казан асар,
Торна килер – тоз салыр,
Саескан килер – салма салыр,
Песнәк килер – пешерер;
Чыпчык килер – төшерер,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Кечтеки түти туймый калыр,
Кетер-кетер, кетер-кетер,
Казан төбен кимерер...



ҮЧТЕКИ

ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫННАН



- Бармак, бармак,
Кайда булдың?
- Бу абый белән баланга бардым,
Бу абый белән ярма ярдым,
Бу абый белән чәй эчтем,
Бу энем белән биергә төштем.

Баш бармак бал ашый,
Имән бармак имән ташый,
Урта бармак утын кисә,
Атсыз бармак ат җигә,
Чәнти бармак чәй эчә.



ҮЧТЕКИ

ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫННАН

Олыга утын ярырга,
Ә сиңа – су китерергә;
Уртага – мичкә ягырга,
Ә сиңа – аш пешерергә;
Чәнтигә җырлый башларга,
Дусларның күңелен ачарга.



Менә минем уң кулым,
Менә минем сул кулым,
Уң кулым, сул кулым,
Менә сиңа куш кулым.



Баш бармак,
Балан ияк,
Урта тияк,
Әби-чәби,
Нәни бәби.

ҮЧТЕКИ


АВТОР БАРМАК УЕННАРЫ (А.Ә.)

Чәбәк-чәбәк,
Сиңа кәрәк!
Чәбәк-чәбәк,
Сиңа сәнәк!
Чәбәк-чәбәк,
Сиңа урак!
Чәбәк-чәбәк,
Сиңа тарак!
Чәбәк-чәбәк
Сиңа тырма!
Син дә тик торма!






Бу бармак - аю,
Бу бармак - бүре,
Бу бармак - төлке,
Бу бармак - керпе,
Бу бармак - тычкан
Өненә качкан!



Ата каз,
Ана каз,
Апа каз,
Абый каз,
Бәби каз:
"Җим калды аз,
Синнән чеметәм бераз"


ҮЧТЕКИ

АВТОР БАРМАК УЕННАРЫ

Песи әйтә “Мияу, мияу!”
Булсын каймак – тау-тау!
Йомшак түшәк – йокларга,
Җылы куллар – сыйпарга!



Ишектә бик зур йозак,
Ачалмадым бик озак!
Бордым,
Суктым,
Тарттым –
Ачтым!
(тәрҗемә)





Байгыш, байгыш,
Әйдә уйныйк качыш!
Тиз-тиз йөгерә тычкан,
Бер адым калмый йомран,
Сикерә йомшак куян,
Шуыша арттан елан.
Тибрәлә-шаулый камыш...
Менә бит минем табыш!

ҮЧТЕКИ

## АВТОР БАРМАК УЕННАРЫ



Бәләкәч үрмәкүчләр
Агачка үрмәлиләр.
Яңгыр үтте сибәләп,
Алар төште тәгәрәп.
Кояш янә елмая,
Үрмәкүч юлга чыга,
Ә нәни үрмәкүчләр
Артыннан калмый чаба.
(тәрҗемә)

Бармакларда ун кошчык -
Песнәк, тургай, сандугач,
Карга, күке, карлыгач,
Карабүрек, сыерчык,
Күгәрчен һәм дә чыпчык.
Көш!!!
Очып чык!

"Без-без" килә бал корты,
Умарта – аның йорты.
Чәчәкләргә куна ул,
Ашарга бал җыя ул!





ҮЧТЕКИ

АВТОР БАРМАК УЕННАРЫ

## Нәни тәпиләр өчен бармак уены

Бер борчак,
Ике борчак,
Өч борчак,
Дүрт борчак,
Биш борчак,
Күп борчак.
Үсеп җитәрләр бер чак,
Хәтфә үлән өстеннән
Тәпи китәрләр шул чак.

*Закирова Әлфия*





Йомарланып йодрыкка
Бармаклар йоклаганнар.
Бергә –бергә бик рәхәт ,
Ләкин торырга кирәк!
Башта торды баш бармак
Имән бармак аннары.
Урта бармак уртада
Зур үскән ул шуңа да.

Атсыз бармак , мин дә , ди
Башкалардан калмыйм , ди
Чәнти бармак иң читтә,
Шуңа үсмәгән һич тә.
Чәнти, чәнти, чәнтеки,
Үсми калган кечтеки
Кети-кети-кети.



*Закирова Әлфия*

ҮЧТЕКИ

АВТОР БАРМАК УЕННАРЫ

Бу бармак- әти,
Бу бармак- әни,
Бу бармак- бабай,
Бу бармак- әби,
Бу бармак- малай,
Яшәве бергә шулай-
Бик күңелле , бик кызык,
Кабатлыйк кызып-кызып:
Бу бармак- әти,
Бу бармак- әни,
Бу бармак- бабай,
Бу бармак- әби,
Бу бармак- кыз.

Күпме шатлык, күпме наз!
Борчулар булсын бик аз!
Бик бәхетле гаилә:
Әти, әни, бабай, әби,
Малай, кыз да биредә,
Яшик гел бергә-бергә,
Булып тату гаилә,
Кушылыгыз Сез безгә!



*Халикова Нурфия*

Бу бармак- кабак,
Бу бармак- борыч,
Бу бармак- кишер,
Бу бармак- кыяр,
Бу бармак- суган.
Яшелчә быел уңган,
Бакчабызда бар да бар!
Шунсы кызык, болар барсы
Кәрзингә ничек сыйган?



Бу бармак- чөгендер,
Бу бармак- сарымсак,
Бу бармак- баклажан,
Бу бармак- помидор,
Бу бармак- бәрәңге.
Бик тиз җыеп бетердек,
Ярый әле өлгердек.
Җәйге яңгыр килеште,
Яшелчәләр тиз үсте.

ҮЧТЕКИ

АВТОР БАРМАК УЕННАРЫ

Әнкәгез сезне эзли,
Кайда сез бармакларым?
Тәмле ашау пешердем,
Сезне искә төшердем.
Баш балама боламык,
Имәнемә икмәгем,



Уртасына урама,
Атсызына катлама,
Чәнти генә калмасын,
Чәкчәген килеп капсын.

*Гаязова Нурия*

"ЧӘЧӘКЛӘР АРАСЫНДА"

Исәнмесез, балалар!
Исәнмесез, дускайлар!
Әйдә чыгыйк бакчага
Күңел ачып, уйнарга.
Аллы-гөлле күбәләкләр
Чәчәкләргә куналар:
Ак чәчәк, ал чәчәк,
Сары чәчәк, күк чәчәк,



Ә монысы - кашкарый
Ул гел кояшка карый.
Шул чәчәкләр арасында
Йөгерешеп уйныйбыз.
Бердәм булгач, барыбыз
Күңелле уеныбыз.

*Муллагалиева Лилия*



ҮЧТЕКИ

АВТОР БАРМАК УЕННАРЫ

Кәҗә, кәҗә-мәкәрҗә,
Кая бардың син кичә?
Бакчабызга кердеңме?
– Юк!!!
Читән аша сикердеңме?
– Юк!
Кәбестәне кимердеңме?
– Юк.
Шалканнарга тидеңме?
– Юк...
Кердең! Сикердең!
Кимердең! Тидең!
Мин беләм!
– Ышанмасаң,
Сөзәм, сөзәм!
(фольклорга ияреп)



Керләр юам, керләр юам,
Сабын сөртәм, ышкыйм, уам,
Ак булсыннар, дим.
Пакь булсыннар, дим.

*Р.Вәлиевадан*

ТӘРӘЗӘНЕ КЕМ ЧИРТӘ?

Тәрәзәне кем чиртә:
Чык-чык! Чык-чык!
Мин килдем шулай иртә,—
Чыпчык, чыпчык.
Бик тә ашыйсым килә.
Чик-чик! Чик-чик!
Йөгереп янына килдем,
Яраткан җимен сиптем.

*Р.Вәлиева*



Диңгездә йөзә балык.
Сикерә, чума,
Чыга калкып.
Бер балык,
Йөз балык,
Артыннан йөзәм талып.

А.Ә.

